ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

19 август, 2015 Казан шәһәре № 84

Гражданнар һәм оешмаларның кергән мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максатында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында статистик хисап формасын расларга (2 нче кушымта).
3. Документаль тәэминат һәм тикшереп тору бүлегенә елына ике мәртәбә, 15 июльгә кадәрге һәм 15 гыйнварга кадәрге чорларда, алга таба Инспекциянең рәсми сайтында анализны 20 июльгә кадәрге һәм 20 гыйнварга кадәрге чорларда урнаштырып, гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясарга.
4. Юридик бүлеккә (Л.Э.Хәйретдиноваga) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
5. Үтәлешен тикшереп торуны җитәкченең беренче урынбасары И.Ф.Сафиуллинга йөкләргә.

Җитәкче В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
2015 елның 19 августындагы
84 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕНӘ ГРАЖДАННАРДАН ҺӘМ ОЕШМАЛАРДАН КИЛГӘН МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРГӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максатында эшләнде һәм гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә (алга таба – Инспекция) мөрәҗәгать итү һәм килгән мөрәҗәгатьләргә (алга таба – мөрәҗәгатьләр) анализ ясау процедурасын билгели.

2. Инспекция җитәкчесенең, җитәкче урынбасарларының, Инспекциянең территориаль органнары җитәкчелегенең (алга таба – гражданнарны шәхсән кабул итүгә вәкаләтле затлар) шәхсән кабул итүе барышында алынган мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат Инспекция аппаратында һәм Инспекциянең территориаль органнарында гражданнарны шәхси кабул итүгә язып алучы затлар тарафыннан анализлана һәм документаль тәэминат һәм тикшереп тору бүлегенә елына ике мәртәбә, 12 июльгә кадәрге һәм 12 гыйнварга кадәрге чорларда тапшырыла.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау документаль тәэминат һәм тикшереп тору бүлеге тарафыннан электрон документ әйләнеше белешмәләрен һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны сайлап алу белән гамәлгә ашырыла.

4. Мөрәҗәгатьләрнең анализында килгән, башка адресларга җибәрелгән һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ әйләнеше формасында килгән мөрәҗәгатьләрнең саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул ителгән гражданнарның күләме турында, гражданнарны шәхсән кабул итүгә вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат, шул исәптән мөрәҗәгатьләр килүгә йогынты ясаучы сәбәпләрне сурәтләп, шулай ук мөрәҗәгатьләр санын киметү буенча тәкъдимнәр белән, кабул ителгән норматив хокукый һәм башка төрле (булган очракта) актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

5. Документаль тәэминат һәм тикшереп тору бүлеге белгече мәгълүматны гомумиләштерә һәм анализлый, ике эш көне эчендә статистик хисапның расланган формасын тутыра һәм анализны килештерү өчен Инспекция җитәкчесенең беренче урынбасарына һәм Инспекция җитәкчесенә җибәрә.

6. Мөрәҗәгатьләргә анализ ачык мәгълүмат булып санала һәм Инспекциянең рәсми сайтында елына ике мәртәбә, 20 июльгә кадәрге һәм 20 гыйнварга кадәрге чорларда урнаштырыла.

ТР ДТК инспекциясенең 2015 елның 19 августындагы 84 номерлы боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында

СТАТИСТИКА ХИСАБЫ<*>

______________________________________________________________ өчен

(ел чорын күрсәтергә: 20___ елның 1 яртыеллыгы, 20___ ел өчен)

| Килгән мөрәҗәгатьләр, барлыгы | Шул исәптән кабат килгәннәре (бер үк мәсьәлә буенча турыдан-туры гражданнардан) | Гражданнар килгән мөрәҗәгатьләр саны | | | | | Гражданнарның мөрәҗәгатьләре буенча килгән гарызнамәләр саны | | | | | | Карау нәтиҗәсе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | почта | курьер | эл. почта | Инт. кабул итү | шәхсән кабул итүдә алынган | ТР ДС | ТР ПА | ТР МКА | М-лыклар, ведомстволар | Прокуратура | ММИ | урынга чыгып тикшерелде | уңай хәл ителде | тискәре хәл ителде (кире кагылды) | башка адреска җибәрелгән | аңлатма бирелде |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Вакытында каралды | Чорын бозып каралды | Мөрәҗәгатьләрне караганда җибәрелгән бозулар өчен дис. җав. | Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | төз. (үзг. коруны) алыр баруның | төзекләндерү | сыйфатсыз төзекләндерү эшләре | микроклимат таләпләре бозылу | инженер системаларын эшләп | башка мәсьәләләр (санап чыгарга) |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тартылды | хокуклы булуы | | | | бетермәү | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

| Мөрәҗәгатьләргә анализ (сурәтләү өлеше) |
|---|
| |

--------------------------------

<*> узган елның аналогик чоры белән чагыштырып төзелә.